Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 3**

Югары Тегермәнлек авылы 2016 елның 3 феврале

Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в»пунктчасы, 18, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башкарма комитетының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 1 февралендәге 4 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 1 февралендәге 2 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. 2016 елның 27 мартына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге уку формасында белем алучы студентлардан,1 төркем инвалидлардан һәм ялгыз яшәүче пенсионерлар (75 яшьтән узган)

тыш балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?

-су челтәрен ремонтлау(тузган су торбаларын алыштыру,насосны алыштыру ) Түбән Тегермәнлек һәм Югары Тегермәнлек торак пунктларында;

- Югары Тегермәнлек һәм Түбән Тегермәнлек торак пунктындагы суүткәргечне һәм су башняларын ремонтлау;;

- 3.Югары Тегермәнлек авылының Гагарин,Совет урамнарындагы, Түбән Тегермәнлек авылының К. Маркс, Мәктәп урамнары буенча янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру;

- Түбән Тегермәнлек торак пунктындагы су башнясы тирәсендә санитар саклау зоналарын урнаштыру.

ЭЙЕ ЮК».

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Тегермәнлек авылы, Совет урамы, 72а йорты; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Түбән Тегермәнлек авылы, Мәктәп урамы, 7А йорты адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгы А.Н.Дмитриев